# МОРФОЛОГИЯ

**§ 1. Морфологиянең өйрәнү предметы һәм бурычлары.** Морфология – грамматиканың бер өлеше. Грамматика – тел белеме фәненең тел төзелешен, сүзләр төрләнешен, җөмлә төзү юлларын һәм ысулларын өйрәнә торган тармагы, һәм ул ике өлештән – морфология һәм синтаксистан тора.

Морфология сүзләрнең төзелешен, төрләнешен, сүз төркемнәрен һәм аларга хас грамматик категорияләрне өйрәнә.

Синтаксис сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне, аларның төзелешен, ясалыш һәм мәгънә буенча төрләрен, җөмлә кисәкләрен һ. б.ны өйрәнә.

Морфологиянең төп өйрәнү предметы – сүз һәм сүзләр төрләнгәндә барлыкка килә торган һәртөрле сүз формалары. Тел белеменең икенче бер тармагы булган лексикологиянең дә төп өйрәнү объекты – сүз. Әмма бу ике өлкәдә сүзләрне өйрәнүнең максаты һәм юнәлешләре төрле.

Лексикологиядә сүзләр лексик мәгънәләре, килеп чыгышы һәм яшәешнең төрле өлкәләрендә кулланылыш үзенчәлекләре ягыннан өйрәнелсә, морфология сүзләрнең төзелешен (морфемика), төрләнешен, ягъни сүз төркемнәренең сөйләмдә күптөрле грамматик формаларда килә алу мөмкинлеген, сүз формаларын, форма ясалышын өйрәнә. Мәсәлән, *китап* сүзе лексикада мөстәкыйль мәгънәле, алынма (гарәптән кергән), бер мәгънәле сүз буларак аңлатылса, морфологиядә ул исем сүз төркеменә караган тамыр сүз булуы, килеш, тартым, сан белән төрләнә алуы ягыннан характерлана. Икенче төрле әйткәндә, морфологиядә сүзләрнең грамматик ягы өйрәнелә.

Агглютинатив (тагылмалы) тел булган татар телендә сүз ясалышы һәм форма ясалышы, нигездә, бер үк чаралар – кушымчалар ярдәмендә башкарыла. Сүз ясалышында сүзнең лексик мәгънәсе үзгәрә, мәсәлән, *кис → кис-әк → кис-кеч → кис-енте*; форма ясалышында исә сүзнең лексик мәгънәсе үзгәрешсез кала, сүзгә яңа грамматик мәгънә өстәлә: *кис → кис-ә → кис-кән → кис-сә.*

Морфологиядә сүзләр сүз төркемнәренә берләштереп өйрәнелә. Аерым сүз төркемнәренең төрләнеше грамматик категорияләрне хасил

итә. Шуңа күрә морфологиянең төп бурычы – телдәге сүз төркемнәре системасын һәм аларга хас грамматик категорияләрне өйрәнү.

**§ 2. Морфологиянең тел белеме тармаклары белән бәйләнеше.** Тел үзенең төзелеше буенча билгеле бер система тәшкил итә. Бу системаның аерым буыннары тел берәмлекләре дип йөртелә. Төп тел берәмлекләре: аваз (фонема), сүз кисәге (морфема), сүз, сүзтезмә, җөмлә. Тел берәмлекләре кечкенәдән зурга таба үсә бара, һәр кечкенә берәмлек зур берәмлек эченә керә. Бу – тел берәмлекләре арасындагы иерархияле мөнәсәбәт дип атала: сүз кисәге (морфема) аваздан яки авазлардан төзелә, сүз – морфемалардан, сүзтезмә – сүзләрдән, ә җөмлә сүзтезмәләрдән тора. Тел берәмлекләренә шулай ук төрлелек, бүленгәнлек һәм бер сызык өстендә килү (линейность) кебек сыйфатлар хас. Лингвистикада бу берәмлекләрне өйрәнүдә дә билгеле бер эзлеклелек бар. Тел белеме тармаклары арасында шуңа күрә үзара тыгыз бәйләнеш яши.

Морфология төп өйрәнү объекты шулай ук сүз булган лексикология белән тыгыз мөнәсәбәттә тора. Сөйләм эчендә сүзнең лексик мәгънәсе һәм грамматик мәгънә берлектә яши. Мөстәкыйль мәгънәгә ия һәр сүз телдә грамматик яктан да формалашкан була. Шул ук вакытта төрле сүзләрнең төрләнү мөмкинлеге, грамматик ягы аларның лексик мәгънәләренә дә бәйле. Сүзләрне төркемләгәндә, мәсәлән, беренче чиратта аларның гомуми лексик мәгънәләре исәпкә алына: исем сүз төркеме – предметлыкны, сыйфат – предмет билгесен, фигыль эш-хәл, хәрәкәтне белдерә һ.б.

Морфологиядә сүз төркемнәренең грамматик категорияләрен өйрәнүгә кадәр, аларның лексик ягы, лексик составы да өйрәнелә. Бу юнәлештә сүз төркемнәре аерым мәгънәви, ягъни лексик-семантик төркемнәргә бүленә. Исем сүз төркеменең семантик төркемнәренә, мәсәлән, ялгызлык һәм уртаклык исемнәр, предметлыкны (*дәфтәр*, *алма*), матдәлекне (*он*, *су*, *тоз*) белдергән һ.б. исемнәр, фигыльдә хәрәкәт фигыльләре (*йөри*, *килә*), эш фигыльләре (*төзи*, *ура*), хис-тойгы фигыльләре (*соклана*, *ярата*) һ.б. керә.

Бер үк сүз төркеменең төрле семантик төркемчәләрендә аерым грамматик категорияләр үзенчәлекле чагылыш табарга мөмкин. Әйтик, исемнәрнең күплек санда килүе предметлыкны яки матдәлекне белдергән исемнәрдә яисә ялгызлык һәм уртаклык исемнәрдә бердәй түгел; хәрәкәт фигыльләренең юнәлеш категориясенә мөнәсәбәте үзенчәлекле һ.б.

Морфология тел белеменең авазларны өйрәнә торган тармагы – фонетика белән дә тыгыз бәйләнгән. Аваз (фонема) һәм морфологиянең өйрәнү предметы – морфема арасында охшаш һәм аермалы яклар бар.

Алар икесе дә телнең иң кечкенә берәмлекләре санала. Әмма морфема ул – сүзнең иң кечкенә мәгънәле кисәге, ә фонема мәгънә аеруга хезмәт итә. Морфема фонемалардан төзелә һәм аваздан яки авазлар җыелмасыннан тора. Мәсәлән, *аш-а*, *сан-а* сүзләрендә ике морфема бар: *аш, сан* – тамыр морфемалар, *-а* – сүз ясагыч кушымча, ул лексик-грамматик мәгънә белдерә, исемнән яңа мәгънәле сүз – фигыль ясый; ә *кал* сүзендәге *а* – фонема, ул мәгънә белдерми, сүз эчендә аны башка аваз белән алыштыру мәгънәне үзгәртә, димәк, фонема мәгънә аеруга хезмәт итә: ***кал*** – ***кол*** – ***кул*** – ***кыл***; *бар-**а*** сүзе шулай ук ике морфемадан тора. Бу очракта *-а* морфемасы фигыль заманын ясый, ягъни ул грамматик мәгънә белдерә.

Татар телендә, сүзләр төрләнгәндә (сүзләргә кушымчалар ялганганда), төрле аваз үзгәрешләре барлыкка килә. Сүзләрнең төрләнеше ул – морфологик күренеш, ә аваз үзгәрешләре фонетикага карый. Димәк, бу очракта фонетика һәм морфология турыдан-туры кисешә. Татар телендә кушымчаларның барлык вариантлары да – фонетик вариантлар, алар һәртөрле аваз үзгәрешләре нәтиҗәсендә барлыкка килә: *-лар*/*-ләр*, *-ды*/*-де*, *-ны*/*-не* (рәт гармониясе); *-ды*/*-де*, *-ты*/*-те*, *-ган*/*-гән*, *-кан*/*-кән* (рәт гармониясе һәм тартыклар охшашлану) һ. б.

Хәзерге фәндә бу өлкәне махсус тел белеме тармагы – морфонология дә өйрәнә башлады. Морфонологиядә сүзләргә кушымчалар ялганганда барлыкка килә торган аваз төрлелекләре өйрәнелә (*-а*/*-ә*, *-ды*/*-ты*, *-ган*/*-кан*).

Морфология грамматиканың икенче бүлеге – синтаксис белән дә тыгыз бәйләнгән. Синтаксисның төп өйрәнү предметы булган сүзтезмәләр үзара грамматик мөнәсәбәттәге сүзләрдән төзелә, ә җөмлә төрле типтагы сүзтезмәләрдән барлыкка килә. Сүзләрнең төрләнеше морфологиядә сүз формалары итеп каралса, синтаксиста алар җөмләдә сүзләр бәйләнешен барлыкка китерүче чаралар һәм җөмлә кисәкләре буларак өйрәнелә. Димәк, морфологиядә дә, синтаксиста да бер үк тел күренешләре өйрәнелә, әмма алар төрлечә бәяләнә. Мәсәлән, *Урманда әле кар ята* дигән җөмләдә *урманда* сүзе морфологиядә – исем, урын-вакыт килешендә, берлектә килгән, килешнең грамматик мәгънәсе урын мөнәсәбәтен белдерү рәвешендә тикшерелә; синтаксиста исә шул ук сүз җөмлә кисәге хәл буларак билгеләнә: урын хәле, хәбәрне ачыклый, хәбәргә урын-вакыт килеше кушымчасы аша бәйләнгән һ.б.

**§ 3. Грамматик категория турында төшенчә. Грамматик форма һәм грамматик мәгънә.** Грамматик категория – сүз төркемнәрен һәм, гомумән, морфологияне өйрәнүдә төп төшенчәләрнең берсе.

Телдәге һәр мөстәкыйль мәгънәле сүз бер үк вакытта ике төрле мәгънә – лексик һәм грамматик мәгънә белдерә, ягъни һәр сүз грамматик яктан формалашкан була. Лексик мәгънәне тамыр яки нигез морфема белдерә, ә грамматик мәгънә сүзнең грамматик формасы (сүзформа[1]) аша белдерелә.

Грамматик категория дип грамматик мәгънә һәм грамматик форма берлегенә әйтәләр. Нәрсә соң ул грамматик мәгънә һәм грамматик форма?

Лингвистикада сүзнең берничә төрле мәгънәсе билгеләнә:

1) лексик мәгънә (аны сүзнең конкрет лексик мәгънәсе дип тә әйтәләр) чынбарлыктагы аерым предмет, күренеш, эш-хәлләрне, билгене һ.б.ны атый. Сүзләрнең бу мәгънәләре, гадәттә, аңлатмалы сүзлекләрдә теркәлә;

2) гомумлексик мәгънә[2] сүзләрне аерым билгеләр буенча гомумиләштерүне күздә тота. Гомумлексик мәгънә дигәндә, «предметлык»ны, «эш-хәл»не, «билге»не һ.б.ны белдерә торган сүзләр кебек төшенчәләр белән эш ителә;

3) грамматик мәгънә күпчелек очракта җөмлә эчендә сүзләр үзара мөнәсәбәткә кергәндә барлыкка килә. *Бала китап укый* дигән җөмләдә *бала – укый* сүзе белән мөнәсәбәткә керә, *бала → укый*; ул башкаручы затны – субъектны белдерә. *Китап* сүзе шулай ук *укый* сүзенә бәйләнгән, *китап → укый*; ул шул эшнең туры объекты була. Ягъни *бала* һәм *укый* сүзләре арасында – субъект мөнәсәбәте, ә *китап* һәм *укый* сүзләре арасында туры объект мөнәсәбәте барлыкка килә. Димәк, грамматик мәгънә – һәрвакыт нинди дә булса мөнәсәбәт ул. Сөйләмдә сүзләр арасында күптөрле мөнәсәбәтләр урнашырга мөмкин, әйтик, *укучының китабы* дигәндә, бу сүзләр арасында ия лек мөнәсәбәте, *урманда кар күп* дисәк, *урманда* һәм *күп* сүзе арасында урын мөнәсәбәте, *иртәгә кайта* дисәк, ике сүз арасында вакыт мөнәсәбәте белдерелә һ.б. Күргәнебезчә, грамматик мәгънә ул – гомумиләштерелгән мәгънә. Грамматика, гомумән, абстракция белән эш итә.

Лингвистикада «лексик абстракция» һәм «грамматик абстракция» дигән төшенчәләр бар. Мәсәлән, *китап* сүзе чынбарлыктагы конкрет бер предметны белдерә, аның конкрет лексик мәгънәсе бар. Әмма бу сүз белән без аерым бер китапны гына түгел, дөньядагы барлык китапларны атый алабыз. Димәк, телдәге һәр сүз гомумиләштерә ала. Бу – лексик абстракция. Ә грамматик абстракция тагын да киңрәк.

---

[1] Бу термин соңгы вакытта чыккан татар теле грамматикаларында кулланыла башлады.

[2] Кайбер хезмәтләрдә ул гомумграмматик мәгънә дип бирелә.

Югарыда китерелгән җөмләдә *бала* сүзе урынына баш килештә килгән башка сүзләрне (*укучы*, *укытучы*, *Алсу* һ.б.) куйсак та, грамматик мәгънә, ягъни эш башкаручыны белдерү үзгәрешсез кала. Шул рәвешле, грамматик мәгънә сүзнең конкрет лексик мәгънәсенә бәйле булмый, ул күбрәк грамматик формага карап үзгәрә. Мәсәлән, *баланы яраталар* дисәк, *бала* сүзенең грамматик формасы үзгәрде (баш килеш урынына төшем килеше), һәм шуңа бәйле рәвештә грамматик мәгънә дә үзгәрә, биредә ул туры объект мөнәсәбәтен белдерә.

Сүз формалары җөмләдәге сүзләр арасындагы мөнәсәбәтләрне генә түгел, чынбарлык күренешләренә яки сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен дә белдерергә мөмкин. Мәсәлән, исемнең к ү п л е к формасы предметларның бердән артык күплеген яки төрлелеген (төрле сортларын) белдерә, фигыльнең з а м а н формалары – эш-хәлнең сөйләү моментына карата үтәлү вакытын, з а т-с а н эшнең кем (кайсы зат) тарафыннан үтәлүен белдерә һ.б. Тел белемендә шуңа бәйле рәвештә грамматик категорияләрне ике төргә бүлеп карау да бар. Җөмлә эчендәге сүзләрнең үзара мөнәсәбәтен белдергән грамматик категорияләр с и н т а г м а т и к грамматик категорияләр дип, ә сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерә торганнары с и н т а г м а т и к  б у л м а г а н грамматик категорияләр дип атала[1]. Синтагматик категорияләргә исемдә – к и л е ш, т а р т ы м, х ә б ә р л е к, фигыльдә з а т-с а н категорияләре керә. Синтагматик булмаган категорияләргә исемдә – к ү п л е к, фигыльдә з а м а н, н а к л о н е н и е, ю н ә л е ш категорияләре, с ы й ф а т  д ә р ә җ ә л ә р е һ.б. керә.

И с к ә р м ә: Синтаксист галимнәрнең сыйфат фигыль һәм хәл фигыль формаларын да синтагматик категорияләргә кертеп караулары беркадәр бәхәс тудыра, чөнки бу кушымчалар, әйтик, *-учы / -үче* (*җырлаучы кыз*, *килүче кеше*), *-ган /-гән* (*җырлаган кыз*, *килгән кеше*), *-асы /-әсе* (*җырлыйсы җыр*, *киләсе кунак*) сыйфат фигыльнең заманнарын белдерәләр, ә заман модаль формаларга, ягъни синтагматик булмаган категорияләргә керә. Сыйфат фигыль белән сыйфатланмыш арасындагы бәйләнеш төрен дә янәшәлек дип билгеләү дөресрәк булыр иде. Шуны да әйтергә мөмкин: сыйфат фигыльләр һәм хәл фигыльләрнең бер үк вакытта сыйфат сүз төркеме һәм рәвеш белән һәр өч яклап (лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик ) уртаклыгы бар. Белгәнебезчә, сыйфатлар һәм рәвешләр үзләре ачыклаган сүзгә янәшәлек юлы белән бәйләнәләр.

Г р а м м а т и к  ф о р м а – грамматик мәгънәләрне белдерә торган морфологик чара. Сөйләмдә грамматик мәгънәне төрлечә белдереп була. Мәсәлән, чынбарлыктагы вакыт төшенчәсен аерым сүз белән

[1] Бу турыда карагыз: Закиев М. З. Введение // Татарская грамматика. – Т. II : Морфология. – Казань, 1993. – С. 16.